| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.05.2021 Буа шәһәре № 137/Бк-к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә җирләү буенча ритуаль хезмәтләр күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешманы сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гомуми принциплар турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Үлгән кешеләрне җирләү буенча хезмәт күрсәтүгә гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы Указы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 декабрендәге 390/ИК-п номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә җирләү буенча ритуаль хезмәтләр күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешманы сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2.4 Пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Мәетләрне җирләү сыйфаты «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законга туры килергә тиеш».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Житәкче вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Шакирҗанов